МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.11.2023 Казан ш № 872

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 19 июлендәге 581 номерлы боерыгы белән расланган Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 19 июлендәге 581 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.07.2016 №438, 08.06.2017 №348, 07.05.2018 №357, 19.09.2018 №887, 26.07.2019 №580, 15.11.2019 №1031, 14.07.2020 №518, 11.12.2020 №847, 20.12.2021 №945, 08.07.2022 №672, 18.11.2022 №1032, 08.02.2023 №71 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль
яклау министрлыгының 2023
елның 13 ноябрендәге 872
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 19 июлендәге 581 номерлы боерыгы белән расланган Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгы (таныклык дубликаты) бирү буенча административ регламентка кертелә торган үзгәрешләр

1.2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Чернобыль АЭС һәлакәте аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 13 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктында күрсәтелгән Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәләрен юкка чыгаруда үлгән кешеләрнең гаилә әгъзалары, шул исәптән тол хатыннары (тол ирләре).»;

2.6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

югалткан таныклыкның табылмавын раслаучы документ, – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

пенсия алу факты турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

бала туу турында – Федераль салым хезмәтеннән;

өйләнешү турында – Федераль салым хезмәтеннән;

тукландыручының үлеме турында – Федераль салым хезмәтеннән;

шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Югарыда аталган белешмәләрне үз эченә алган әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.»;

3.4.1 һәм 3.4.2 пунктларны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Идарә (бүлек) белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

пенсия алу факты турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

бала туу турында – Федераль салым хезмәтеннән;

өйләнешү турында – Федераль салым хезмәтеннән;

тукландыручының үлеме турында – Федераль салым хезмәтеннән;

шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан.

3.4.2. Таныклык (таныклык дубликаты) бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Идарәдә (бүлектә) булмаганда, Идарә (бүлек) белгече, шул исәптән электрон рәвештә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә.

Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи зат әлеге Регламентның 2.6.3 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, сорала торган документлар исемлеге:

пенсия алу факты турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

бала туу турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

өйләнешү турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

туендыручының үлеме турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

шәхси счетның иминият номеры турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә.

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.».